ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**« 28 » апрель 2021 ел** **№ 9**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү Тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 174[3] статьясы, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен һәм салым чыгымнары исемлеген төзү Тәртибен кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә 1 сентябрьгә кадәр Татарстан Республикасы Яңа Кишет авыл җирлеге Башкарма комитетына хисап елы, хисап елына кадәрге ел өчен түбәндәге белешмәләрне җибәрергә тәкъдим итәргә:

ташламалардан файдаланучы түләүчеләр саны турында;

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге бюджетының һәр салым чыгымы буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге бюджетыннан төшеп кала торган керемнәре суммалары турында.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http://arsk.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Э.Ф.Минҗанова